# Traditional Decorative Leather Art of the Tatars: *Kaiyly Kün*



*In English: pages 1-3* *Тамарча: 4-6 бит*

The Tatar traditional decorative art, including one-of-a-kind *Kaiyly Kün,* has been formed and influenced by practices and beliefs of various historic communities of EurAsia: Sakas (Scythians), Turkic nomads, Volga-Ural indigenous inhabitants, and Muslims, to name most prominent. Traditionally, Tatar craftsmanship is expressed through a combination of floral, vegetative, zoomorphic, and geometrical ornamental elements, and with such materials as processed animal skin, animal hair, plant fibers, stone, clay and metal.

The oldest material - animal skins and hides – were utilized by humans for survival since prehistoric times and became more valuable with the progression of tanning and dressing technologies. Among the reputable and sought-after processed leather was the one mastered by the skillful people of the (Volga /*Itil*) Bulgaria - one of the first and largest feudal state of Eastern Europe of the $8^{th}$-$13^{th}$ centuries[1] - whose descendants are nowadays referred to as the Tatars. The legacy of famous high quality soft aromatic leather that once was the pride and fame of the Volga Bulgars[2] has slowly been vanishing. The leather tanned with exceptional technology produced by the Volga Bulgars became referred to as *bulgari* in the Middle Ages[3]. *Bulgari* is thought to be utilized as an umbrella term for two types of leather: 1) *juft/yut* (either from Persian جفت meaning *"pair"* or Bulgarian «ўт» meaning "*leather*"), and 2) *safyan/ sahtiyan* (from Persian ساخته "*saht*" meaning "*fit/processed/made*"). These terms, *originally and primarily*, had referred to the goat (*safyan*) and the sheep (*yut*) hides tanned with willow bark, colored by plant-derived dyes and oiled by birch tar. In $18^{th}$ to early $20^{th}$ centuries, valuable high qaulity soft colored leather with a distinctive aroma (acquired during the tanning and oiling with birch tar) was manufactured using the technologies mastered by the Volga Bulgars. It became referred to as "*Russia*" leather in the Western literature[4].

The Volga Bulgars had inherited their artistry, creativity and spirituality from the nomadic people of the EurAsian steppes: examples are in expressive and exceptionally stylyzed artifacts of so-called Scytho-Siberian world of $7^{th}$ to $3^{rd}$ centuries BCE (before common era) housed in Hermitage, etc.[5] After the adoption of Islam in 922[6], the Volga Bulgars embraced Islamic aesthetics, particularly symmetry and natural harmony in their artistic expressions[7]. Those integral features, along with the mastery of the quality leather processing and leather footwear craftsmenship, have been passed through generations to the successors of the Volga Bulgars, who came to be known as the Tatars in the modern times.

Fragments of quality decorated footwear as well as leather working tools, scraps, equipment, and workshops were excavated[8] in:

- **Bulgar** – a powerful trading center that connected Silk Road, Volga Trade Route, and Muslim world networks in Middle Ages;
- **Kazan Kremlin** – a citadel of Kazan Khanate, a Muslim state that flourished between 1438 (after Ulug Ulus) and 1552 (conquest by Christian Muscovite Tsardom).




**Fragments of leather footwear produced by Volga Bulgars (ancestors of modern Tatars)**

Excavated in Bulgar, 11-13 centuries. Decorated with embossing technique — Excavated in Kazan Kremlin, 15-16 centuries. Decorated with gold embroidery

During the rule of Muslim khans of Volga Bulgaria, Ulug Ulus, Kazan Khanate, and pre-industrial Christian-powered Muscovite Tsardom, Rossiyan Empire, the leather processing and leather goods productions had been carried within "professional and folk artistic traditions"[9]: a combination of religio-political and aristocracy-dictated canonic manufacturing and collective artistic experiences of individual crafters. By the mid-19th century, the large leather processing plants and footwear manufactures were established by the Tatar as well as other ethnic entrepreneurs in Kazan city-Arshcha province areas. Apart from Kazan-surrounding areas, industrious Tatar craftspeople had opened workshops in the towns of the Rossiyan Empire, Central Asia/ Turkestan, Middle East, and the Caucasus.

1. *Drevnee Iskustvo Tatarii, F. Valeev, G.Valeeva-Suleimanova, 1987, p.59-65*
2. *Povest' Vremennykh Let, 12-15 centuries, 1996, p.7, p.39: year 985 (6493)*
3. *Kazanskya Uzornaya Kozha, 2004, Səhtiyan Shchiteq, Sauryi Ükshche, 2013, L.Sattarova, 2013, p. 7-23*
4. *The Manufacture of Leather, C.Davis, 1885, p.65-68*
5. *Frozen Thombs of Siberia, S.Rudenko, 1953 . Hermitage museum, St. Petersburg, Rossiyan Federation*
6. *Risalya (Travel from Bahdad to Volga/Bulgaria in 921-22), A. Ibn Fadlan, ~10 century with following transaltions & publishings*
7. *What is "Islamic" Art?: Between religion and Perception, W. Shaw, 2019*
8. *Tatar Costume:From Collection of the Tatarstan republic's State Museum, M.Zavyalova, 1996, p.23, 33*
9. *Art Encyclopedia: Terms Related to the Traditional art of Uzbekistan, E. Gyul, 2023, p.188*



***Overview by Shchulpan Hismatva. April 2026.***




Exceptionally decorated (*kaimaly*) ***shchiteq**** – a Tatar word for a "soft (ornamented) leather sock-like boot" – were favored by the Tatar Muslim and Russian Orthodox aristocracy. They gained iconic popularity in the Russian and Ottoman Empires, Turkistan (countries of Central Asia), Europe and America: the world museums keep records in their collections[1].

At the verge of the 19th and 20th centuries, leather manufacturing was the second high-volume, high-profit business in Kazan (after fabric weaving)[2]. Skillfully crafted with unique *Kaiyly Kün* technology, Tatar boots - **shchiteqler* -** became part of many fashionable and powerful people's wardrobes after being displayed at many World Fairs, including: London in 1851, Philadelphia in 1876, Chicago in 1893, and Paris in 1925.

The rest of the 20th and early 21st century (establishment of the Union of Soviet Socialist Republics/USSR in 1922, its collapse in 1991 and establishment of Rossiyan**Federation) can be marked as challenging for Tatar leather processing and footwear craftmanship: almost all large manufacturing entities either ceased to exist or continue to operate with small scale production. Nowadays, the art of Kaiyly Kün is being practiced by individual craftspeople, designers, and very small-scale businesses in the Kazan-Arshcha area of Tatarstan Republic.

The **Kaiyly Kün** technology is a unique artistic form created and mastered by the Volga Bulgar-Tatars. The Tatar term *кайылы (kaiyly) кун* (*kün)* means "soft leather that is embellished along its edges"[3]. In English, the best alternative is *Tatar Leather Mosaic;* the terms *inlaid leather, patterned leather, mosaiced leather, uzornaya kozha and incorrect* are also found in literature.

**КАЙЫ-У (каеды, каю) «вышивать по краю; отсрочить; строчить»** ~ гом. кыпч., алт. кайы-, угыз. гайы- < бор. төрки *qaδı- id.; борынгыдан бирле кайу исеме дә килә: алт. kājы, каз. )айу, кырг. )а йуу, )айу) «эре жөй» < бор. төрки (МК) qaδıγ id. < *qaδ-ı-γ, чаг. тув. диал., хак. хай- «каймалау». Räsä nen 1969: 221; Joki 1952: 152; Федотов II: 305 (Кыю II сүзе белән чагыштыра). Чаг. Кый. Дерив.: каел-у, кает-у. К. Каеш, Кайма.

Tatar Etymology Dictionary, R. Akhmetyanov, 2015




The <u>uniqueness of **Kaiyly Kün** technology</u> and its ultimate three-dimentional application, *shchiteq,* <u>is in **complex** integration of **three elements**</u>:

1. **curvylinear colorful soft leather cutouts**,
2. aligned /stacked to create **elaborate Turkic-inspired designs**,
3. attached with **distinct manual inward stitching** in a manner that cannot be reproduced by a machine. In this process, three loops of a twisted decorative thread are circled around a sturdy waxed thread, squeezed between two leather cutouts, and fixed with another waxed thread. This distinct stitching in traditional shchiteqler performs dual function: It holds and it embelishes simultaniously.

Interestingly, the stitch employed in Kaiyly Kün is originated from an ancient inward two-thread/two-needle stitch. A Tatar original word for it is lost (not identified); since mid-19th century it has been recorded to be called as *Kazan* stitch referring to the epicenter for the unique leather craftsmanship. Instances of leather items created in areas of Central Asia, Middle East, Balkans, and North Africa also employ a variation of this distinct stitching. In particular, it is widely utilized nowdays[3] by Moroccan leather craftspeople and is referred as "*sarma"*- the word derived from Turkic root "*sar-"* meaning to "*wrap around"*[4]. It is very likely that the Bulgar-Tatars also had used this terminology. **Although the technique of the stitch is not unique, the way the Volga Tatars have been untilizing the stitch to create complex and intricate designs had no analogy.**

**САРМА-У** диал. **«обвивать» сар-у (к.)** сүзенең интенсивлык формасы. Дерив.: сармал-у, сармат-у, сармаш-у. **САР-У «облеплять; наматывать, обматывать»,** башк. Ар- < гом. Төрки сар-, сары-, сару-, тув. Шары- id. ~ чув. **Сыр-, сăр- «кием (бигрәк тә чолгау h.б.) кию».** Будагов I: 685; Радлов IV: 314, 321, 324; Räsänen 1969: 402;

*Tatar Etymology Dictionary, R. Akhmetyanov, 2015*




*Kazan* stitching on the bag crafted in Tatarstan, ~2000



*Sarma* stitching on the bag crafted in Morocco, ~1980

1. *Museum Tatar Boots, www.UniqueLeatherMosaic.com, 2011-2026*
2. *Tatar Industrialist, S. Belov, 2017, p.5-6*
3. *Exploring the Labyrynth in Marrakesh, www.UniqueLeatherMosaic.com, February 2025*
4. *Etymology Dictionary of Tatar Language, R. Akhmetyanov, Institute of Tatar Language, Literature and Culture of Tatarstan, 2015.*

*Pronunciation of "shchi-" in "shchiteq" is close to "*chi*" in "*Chicago*". *Shchiteq* is singular. *Shchiteq**ler*** is plural.

**Rossiyan (Federation) is the original adjective of the country widely accepted in English as Russian (Federation). Rossiyan encompasses more than *Russian*.

Stylised motifs of sprouts, leaves, palmettes, flowers, clouds, wings, antlers, horns appear in the decorative art of the Tatars[1] displaying an understanding of the world that is rooted in ancient times. A durable surface of the leather footwear offers an excellent canvas to showcase human harmony that is closely connected with nature and spiritual power of Umay and Tengri. Along with the Tatars, these dieties and life-supporting elements of the natural world have been inspiring a material culture of many other Turkic people who share common historic, lingustic and customary foundations[2]. However, only the Volga Bulgar-Tatars harnessed the potential of the leather footwear to tell a story through ornamentation, thus locking the archaic symbolic designs. In traditional ***kaimaly shchiteqler***, each decorative element is aligned in a meaningful, wholesome design featuring key universal aspiration for wellbeing, value of family, fertility, respect to maternal and higher powers, admiration of beauty, and a wish for fullfilled life[3].



late 19th -early 20th century



mid-20th century






late 20th -early 21st century

Traditional ***kaimasyz***[4] (opposite to kaimaly) ***shchiteq***, a tall sock-like boot of dark colored soft leather, comes with either no decoration or minimal ornamentation on the back of the heel made of *sauryi /shagreen* (from Turkic "*sağr"* meaning *"rawhide of horse/donkey's back*") - a distinctly looking green-colored leather processed with copper and pebbles. In Muslim world of Turkic-speaking population (~200 million as of 2026), this type of footwear (tall or shortened) is reffered as *masi/maskh* (*from Arabic* مسْ *"mash" meaning "to wipe"*)[5] and worn with outer shoes (as any shchiteq before early 20th century). They are indented to be kept on when entering the mosque for prayer after wiping them off during ablution. Nowadays, there is no known mass production of kaimasyz shchiteqler in Tatarstan.











**Modern shchiteqler made in Tatarstan are**

- *kaimaly*, with full or partial ornamentation that is mostly modelled from earlier designs, with limited innovative elements.
- made of leather that is (mostly) not processed locally and have hard leather sole protected with durable rubber
- short- or high-heeled, that is, usually, done with traditional stacked leather technology
- limited edition and, occasionally, custom-made
- produced by a small number of artisans and small businesses in Kazan-Arsk area of Tatarstan.

In 2025, shchiteqler prices ranged between 200 and 800 USD. The public demand for Tatar footwear picked up since 2020, resulting in more affortable offerings. Other leather items with Kaiyly Kün designs (bags, shoes, pillows, wall art, chests, small furtiture, etc.) are in much greater supply by a variety of small vendors.

CC BY-SA 4.0
**Content and images are courtesy of https://uniqueleathermosaic.com. Citing is required when used, shared and/or manipulated.**

**Visit www.UniqueLeatherMosaic.com to learn more about unique art of the Tatars, Kaiyly Kün.**

1. *Tatarskyi Narodnyi Ornament, F. Valeev, 2002, p.269-277*
2. *Inaugurating Turkic Languages Day, www.UniqueLeatherMosaic.com, December 2025*
3. *Kozhanaya mozaika:Teatr-zhivopis' Naili Koumysnikovoi, 2013, p.28-36*
4. *Kəzhül shchiteq, G.Iskhaki, 1919 (orginal text in Arabic script,text in Latin script, text in Cyrillic script, audio in Tatar original)*
5. *Discovering Tatar Boots in Bukhara, www.UniqueLeatherMosaic.com, July 202*



***Overview by Shchulpan Hismatva. April 2026.***

# Татар халкының бизәлеш сәнгате: *Кайылы күн*



Татар халкының традицион бизәлеш сәнгате, шул исәптән *кайылы күн*, төрле тарихи берләшмәләрнең - сакалар, төрки күчмә халыклар, Идел-Урал төбәгенең җирле кабиләләре, мөселманнар - махсус дөньяны күзаллау тәэсирендә формалашкан. Гадәттә, һөнәр осталыгы чәчәк, үсемлек, зооморф һәм геометрик бизәкләрне берләштерүдә сизелә. Шулай ук, эшкәртелгән хайван тиреләре, йоннары, үсемлек җепселләре, таш, балчык һәм металл материалларны куллануда чагыла.

Борынгы чимал- хайван тиресе - кешеләр тарафыннан күптән, элеккеге заманнан, яшәү өчен кулланылган. Күн эшкәртү ысулларының үсеше бу чималны тагын да затлырак иткән. Ихтыяҗлы нәфис эшкәртелгән күннәр арасында Идел буе Болгар - VIII-XIII гасырларда көчле дәүләт - халкы тарафыннан үзләштерелгәннәре дә бар[1]. Идел буе болгар-татарларның элек горурлыгы һәм дан-шөһрәте булып танылган югары сыйфатлы, йомшак, хуш исле күн мирасы[2], кызганыч, әкренләп онытылып бара. Идел буе болгарлары уйлап тапкан гаҗәеп технология буенча эшләнгән күн, урта гасырларда *болгари* дип атала башлаган[3]. *Болгари* ике төр күнне аңлату өчен кулланыла дип санала: 1) *юфт* (фарсыча جفت сүзеннән "*пар*", яки иске болгарча "*өт*" сүзеннән "*тире*" мәгънәсендә) һәм 2) *сафьян/сахтиян* (фарсыча ساخته "*сахт*" сүзеннән "*яраклы/эшкәртелгән/ясалган*" мәгънәсендә). Бу терминнар, башта һәм нигездә, тал кабыгы белән эшкәртелгән, үсемлекләрдән алынган төсләр белән буялган һәм каен дегете белән майланган кәҗә (*сафьян*) һәм сарык (*юфт*) тиреләрен аңлата иде. XVIII гасырдан XX гасыр башына кадәр, каен дегете белән эшкәртелгән үзенчәлекле хуш исле йомшак күн, Идел буе болгарлары технологияләре буенча эшләнә һәм көнбатыш әдәбиятында "*Раша/ Русия /Russia*" күне дип атала[4].

Идел буе болгарлары ЕврАзия далаларының күчмә халкыннан сәнгатьне, иҗатны һәм рухиятне мирас итеп алганнар, моңа мисал, безнең эрага кадәр, VII-III гасырлардагы скиф /сака - себер дөньясының экспрессив һәм гадәттән тыш стильләштерелгән Эрмитаждагы артефактлар[5]. 922 елда[6] ислам дине кабул ителгәннән соң, мөселман Идел буе болгарлары ислам эстетикасын, аерым алганда, үзләренең сәнгать иҗатында симметрия һәм табигый гармонияне үзләштергәннәр[7]. Бу бәхәссез факторлар сыйфатлы күн эшкәртү һәм күн аяк киемен бизәү осталыгы белән буыннан-буынга күчеп килеп, хәзерге заманда татарларга варисларча тапшырылган.

Казу эшләре барышында сыйфатлы бизәлгән аяк киеме кисәкләре, шулай ук күн эшкәртү, кисү өчен кораллар, җиһазлар һәм остаханәләр табылган[8] урыннар:

- **Болгар** - урта гасырларда бөек Ефәк юлын, Идел буе сәүдә юлын, мөселман дөньясын тоташтыручы көчле сәүдә үзәге;
- **Казан Кремле** - 1438 ел (Олуг Улус-Алтын Урдадан соң) һәм 1552 ел (Мәскәү христиан патшалыгы тарафыннан яулап алыну) арасында чәчәк аткан мөселман дәүләте- Казан ханлыгының ныгытылган корылмасы.




**Татарлар-Болгарлар эшкәрткән аяк киемнәре**

Болгарда казып чыгарылган. XI-XIII гасыр. Эмбосс/ рельеф технологиясы белән бизәлгән

Казанда казып чыгарылган. XV-XVI гасыр. Алтын чигү технологиясы белән бизәлгән

Идел буе Болгары, Олуг Улус, Казан ханлыгы һәм индустриаль чорга кадәрге христианнар тарафыннан идарә ителгән Мәскәү патшалыгы, Россия империясе, күн эшкәртү һәм күн әйберләре җитештерүне "һөнәри һәм халык сәнгате традицияләре"[9] кысаларында алып барганнар: дини-сәяси, аксөякләр тарафыннан билгеләнгән канон җитештерүне, шулай ук заман таләпләренә туры китереп, аерым һөнәрчеләрнең коллектив сәнгать тәҗрибәләренә берләштергән. XIX гасыр уртасына татар һәм башка халык эшмәкәрләре эре күн эшкәртү артельләре һәм аяк киеме җитештерү мануфактураларына нигез сала. Казан тирәсеннән тыш, тырыш татар һөнәрче-сәүдәгәрләр Россия империясе, Урта Азия/ Төркестан, Якын Көнчыгыш һәм Кавказ шәһәрләрендә остаханәләр ачканнар.

1. *Древнее искусство Татарии, Ф. Валеев, Г. Валеева-Сулейманова, 1987, 59-65 бит.*
2. *Повесть временных лет, 12-15 век, 1996.7,.39 бит.: 985 (6493) ел*
3. *Səhtiyan Shchiteq, Sauryi Ükshche, 2013, Л. Саттарова, 2013, 7-23 бит.*
4. *The Manufacture of Leather, C.Davis, 1885, 65-68 бит.*
5. *Frozen Thombs of Siberia, S.Rudenko, 1953* . Эрмитаж коллекциясы, Санкт Петербург, Россия Федерациясы
6. *Risalya (Travel from Bahdad to Volga/Bulgaria in 921-22), A. Ibn Fadlan, ~10 гасыр*
7. *What is "Islamic" Art?: Between religion and Perception, W. Shaw, 2019*
8. *Татарский костюм: Из коллекции Национального музея Республики Татарстан, М.Завьялова, 1996, 23, 33 бит.*
9. *Энциклопедия искусства: Термины традиционного искусства Узбекистана, Э.Гюль,2023, 188 бит*




mid-19th century

late 19th -early 20th century

Гадәттән тыш бизәлгән **(каймалы) читек** (әдәби грамматик язылуы буенча “*читек*”, фонетик язылуы буенча *“щитэк”) “йомшак (бизәкле) күннән, бина эчендә кия торган итек”* дигәнне аңлата. Татар мөселман һәм рус православие аристократлары тарафыннан яратып кабул ителеп, XVIII гасырдан башлап, татар читекләре Россия һәм Госман империяләрендә, Төркестанда, Европада һәм Америкада популярлык казанган. Дөнья музейлары үз коллекцияләрендә шундый мәгълүмәтләр саклый[1].

XIX һәм XX гасырлар чигендә күн житештерү Казанда икенче зур күләмле, югары табышлы бизнес булган (тукыма тукудан соң)[2]. Уникаль *кайылы күн* технологиясе белән оста эшләнгән татар читекләре, Бөтендөнья күргәзмәләрендә, шул исәптән: 1851 елда Лондонда, 1893 елда Чикагода һәм 1925 елда Парижда - тәкъдим ителгәннән соң, күп кенә модалы һәм абруйлы кешеләр гардеробларында урын ала башлый.

XX гасырның калган өлешен (1922 елда Совет Социалистик Республикалары Берлеге оешу, 1991 елда аның таркалуы һәм Россия Федерациясе оешу) татарның югары сыйфатлы күн эшкәртү һәм аяк киеме һөнәрчелеге өчен катлаулы чор дип билгеләп үтәргә мөмкин: барлык диярлек эре житештеру оешмалар юкка чыга, яисә әз күләмдәге житештерү белән шөгыльләнә. Хәзерге вакытта *кайылы күн* сәнгате белән Татарстанның Казан шәһәрендә һәм Арча районында аерым һөнәрчеләр, дизайнерлар һәм вак эшмәкәрләр шөгыльләнә.

**Кайылы күн** технологиясе Идел буе татарлары тарафыннан иҗат ителгән һәм үзләштерелгән уникаль сәнгать формасы. Татар телендә *кайылы (каюлы) күн* "*кырыйлары буйлап бизәлгән йомшак күн*"[4] дигәнне аңлата. Инглиз телендә бу технологияны *Tatar leather mosaic* дип әйтеп була; әдәбиятта шулай ук *inlaid/ patterned/ mosaiced leather, intarsia* терминнары да очрый. Рус телендә аны *узорная кожа* дип дөрес итеп йөртәләр иде, әммә *кожаная мозаика* хәзерге заманда күбрәк ишетелә.

**КАЙЫ-У (каеды, каю) «вышивать по краю; отсрочить; строчить»** ~ гом. кыпч., алт. кайы-, угыз. гайы- < бор. төрки *qaδı- id.; борынгыдан бирле кайу исеме дә килә: алт. кāјы, каз. )айу, кырг. )а йуу, )айу) «эре җөй» < бор. төрки (МК) qaδıγ id. < *qaδ-ı-γ, чаг. тув. диал., хак. хай- «каймалау». Räsä nen 1969: 221; Joki 1952: 152; Федотов II: 305 (Кыю II сүзе белән чагыштыра). Чаг. Кый. Дерив.: каел-у, кает-у. К. Каеш, Кайма.

Tatar Etymology Dictionary, R. Akhmetyanov, 2015




<u>**Кайылы күн**</u> <u>технологиясенең</u> <u>**уникальлеге**</u> (һәм аның өч үлчәмле кулланышы, *читек)*, <u>**өч элементны катлаулы берләштермәдә**</u>:

1. төрле төсле, йомшак, дугасыман күн кисемтәләре;
2. борынгы төрки илһамлы катлаулы үрнәкләргә нигезләнгән һәм бер-берсенә туры китерелгән;
3. махсус кул җөе белән тискәре ягыннан тегелгән. Бу җөйне тегү машинасы белән кабатлап булмый. Кайы процессы барышында бормалы декоратив бауның өч элмәге нык тоташтыручы балавыз җеп тирәли әйләндереп алына һәм ике күн кисемтә арасына кысыла. Традицион читекләрдә бу үзенчәлекле җөй ике функция үти: ул тотып тора һәм бизи.

Шунысы кызык, кайылы күн тегүендә кулланылган җөй борынгы эчке ике җепле/ике энәле тегүдән килеп чыккан. Бу төр тегүнең, нигездә, татарча исеме югалган (билгеләнмәгән); XIX гасыр уртасыннан аны “Казан җөе” дип атый башлаганнар. Азия, Якын Көнчыгыш, Балкан һәм Төньяк Африка төбәкләрендә эшләнгән күн әйберләрендә шулай ук бу җөй кулланыла. Аерым алганда, ул хәзерге вакытта[3] Марокко күн осталары тарафыннан киң кулланыла һәм "*сарма*" дип атала: бу сүз төрки "*sar-*" тамырыннан килеп чыккан, "*урап (чорнап) алу*"[4] дигәнне аңлата. Болгар-татарлар да бу терминны кулланганнардыр дип фаразларга мөмкин. **Бу җөй ысулы башка халыкларда кулланса да, катлаулы кайылы күн сәнгате татарларда гына теркәлгән.**

**САРМА-У** диал. **«обвивать» сар-у (к.)** сүзенең интенсивлык формасы. Дерив.: сармал-у, сармат-у, сармаш-у. **САР-У «облеплять; наматывать, обматывать»,** башк. Ар- < гом. Төрки сар-, сары-, сару-, тув. Шары- id. ~ чув. **Сыр-, сăр- «кием (бигрәк тә чолгау һ.б.) кию».** Будагов I: 685; Радлов IV: 314, 321, 324; Räsänen 1969: 402;

*Tatar Etymology Dictionary, R. Akhmetyanov, 2015*




*Казан* җөе Татарстанда эшләнгән букчада, ~2000



*Сарма* җөе Мароккода эшләнгән букчада,~1980

1. *Museum Tatar Boots, www.UniqueLeatherMosaic.com, 2011-2026*
2. *Татарские промышленники, С. Белов, 2017, 5–6 бит.*
3. *Exploring the Labyrynth in Marrakesh, www.UniqueLeatherMosaic.com, февраль ае 2025 ел*
4. *Татар теленең этимологик сүзлеге, Р. Әхмәтьянов, Татарстанның тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2015*

Татарларның декоратив сәнгатендә[1] үсентеләр, яфраклар, пальметталар, чәчәкләр, болытлар, канатлар, мөгезләр һәм аларның стильләштерелгән мотивлары күренә. Алар борынгы заманнарга барып тоташкан дөньяны аңлауны күрсәтә. Күн аяк киеменең нык өслеге табигать, Умәй һәм Тәңренең рухи көче белән тыгыз бәйләнгән гармониясен күрсәтү өчен иң яхшы нигез булып тора. Бу илаһлар һәм табигать дөньясының тормышны тәэмин итүче элементлар, татарлар белән беррәттән, уртак тарихы, тел һәм гореф-гадәт нигезләре булган, башка күп төрки халыкларның матди мәдәниятенә илһам булып хезмәт иткән[2]. Бары тик Идел буе болгар-татарлары гына борынгы орнамент ярдәмендә, онытылган символик бизәкләрне торгызып, күн аяк киеме аша тәкъдим иткәннәр. Традицион каймалы читекләрдә һәр декоратив элемент мәгънәле, тулы дизайнда урнаштырылган: анда иминлек, гаилә кыйммәтләре, уңдырышлылык, Ана һәм югары көчләргә хөрмәт, матурлыкка соклану һәм тулы канлы тормыш өчен төп символик гомумкешелек омтылышлары күрсәтелгән[3].



late 19th -early 20th century mid-20th century late 20th -early 21st century



Традицион **каймасыз**[4] (каймалыдан аерма буларак) **читекләр -** кара төстәге йомшак күннән эшләнгән оекбаш сыман итек - ул бизәксез, кайбер вакытта үкчәсенең *саурыйы* (төрки *sağr* сүзеннән, "*ат/ишәк аркасы тиресе*" дигәнне аңлата, ул бакыр һәм вак ташлар белән эшкәртелгән яшькелт төстәге күн) минималь бизәк белән эшләнгән. Төрки халык мөселман дөньясында каймасыз читекне (озын яки кыска) шулай ук *маси/мәсх* дип йөртәләр (гарәп مَسَحَ сүзеннән, "сөртү" дигәнне аңлата)[5]. Алар өске аяк киеме, кәвешләр, белән киелә (XX гасыр башына кадәр бөтен читекләр шулай киелгән). Тәһәрәт алып һәм кәвешне салып, масих кылган (сөрткән) читекләр белән мәчеткә намазга керергә рөхсәт ителгән. Хәзерге вакытта Татарстанда каймасыз читекләр ясаулары билгеле түгел.




**Татарстанда житештерелгән заманча читекләр**:

- каймалы, тулысынча яки өлешчә бизәкле
- нигездә жирле дәрәҗәдә эшкәртел*мәгән* күннән эшләнгән
- каты күн табаны нык резина белән сакланган
- тәбәнәк яки биек үкчәләре, кагыйдә буларак, кат-кат өелгән күн технологиясе буенча эшләнгән
- чикләнгән данә белән чыгарыла һәм, гадәттә, заказ буенча эшләнә
- Татарстанның Казан шәһәрендә, Арча районында исемнәре аталмаган ике-өч эшмәкәр һәм берничә кечкенә брендлы фирмалар тарафыннан житештерелә
- 2020 елдан халыкның татар аяк киеменә ихтыяҗы артты, бу исә аңа бәяләр артуга китерде. 2025 елда аларның бәяләре 25-100 мең сум арасында булды.

Кайылы күн бизәкләре белән эшләнгән башка күн әйберләре (букчалар; мендәрләр; дивар, сандык һәм җиһаз бизәкләре, һ.б.) төрле вак эшмәкәр-сәүдәгәр тарафыннан күпкә күбрәк тәкъдим ителә.

**Фотолар һәм контент https://uniqueleathermosaic.com рөхсәте белән бирелгән. Кулланганда, бу платформага сылтама мәҗбүри.**
CC BY-SA 4.0

**Кайылы күн сәнгате турында күбрәк беләсегез килсә, www.UniqueLeatherMosaic.com сайтына кереп чыгыгыз.**

1. *Татарский народный орнамент, Ф. Валеев, 2002, 269-277 бит.*
2. *Inaugurating Turkic Languages Day, www.UniqueLeatherMosaic.com, декабрь ае 2025 ел*
3. *Казанская мозаика: Театр-живопись Наили Кумысниковой, 2013, .28-36 бит.*
4. *Кәҗүл читек, Г. Исхаки, 1919 (Оригиналь гарәп графикасында текст, Латин графикасында текст, Кирилл графикасында текст, Татар телендә аудио язма)*
5. *Discovering Tatar Boots in Bukhara, www.UniqueLeatherMosaic.com, июль ае 2020 ел*



***Гомуми күзәтү. Щулпан Хэзмэтва. 2026 ел, апрель ае.***